ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
“АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ “
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«АКСУБАЕВСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**СУНЧЕЛЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
423052, Республика Татарстан, Аксубаевский муниципальный район, село Сунчелеево, ул. Ленина, 76.
Тел. (8-84344-4-98-24) ОГРН 1061665002080,
ОКПО 94318582, ИНН/КПП 1603004776/160301001

# КАРАР

№ 10 2021ел, 17 ноябрь

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге Башкарма комитетының «2018-2035 елларга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын раслау турында» 15.03.2018, № 3 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003, № 131-ФЗ Федераль закон нигезендә, норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлеге Башкарма комитетының «2018-2035 елларга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын раслау турында» 15.03.2018, № 3 карары белән расланган 2018-2035 елларга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Сөнчәле авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Программаның паспортында: «Халыкны социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин итүнең максатчан күрсәткечләре (индикаторлары)» юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | |
|---|---|
| Социаль инфраструктура объектларын проектлау, төзү, реконструкцияләү буенча планлаштырылган чараларның (инвестицион проектларның) тасвирламасы | 2019 елда МСУ бинасы төзелеше |

2) 1.4 пунктның 3 абзацында «муниципаль заказны формалаштыру» сүзләрен «муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга; «максатчан» сүзен «дәүләт, республика, муниципаль» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Сөнчәле авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: И.В.Крайнова